**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

# КАРАР

от 25 декабрь 2019 ел. № 388

Әтнә муниципаль районында 2020
елга торак-коммуналь хезмәтләр
күрсәтү тарифларын раслау турында

2004 елның 30 декабрендәге 210 номерлы Федераль закон нигезендә. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя хасил итү нигезләре һәм тарифларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары, «2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь)индекслары турында " Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 14 декабрендәге 746 номерлы Указы», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 ел, 29 июнь, 450 нче карарына үзгәреш кертү хакында " 2019 ел, 3 декабрь, 1097 нче карары нигезендә Әтнә районы башкарма комитеты карар итә:

1. 2020 елга расларга һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан һәм 2020 елның 1 июленнән Әтнә муниципаль районы территориясендә гамәлгә кертергә:

- муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга һәм торак урыннары милекчеләренә торак хезмәтләренә тарифлар, №1 кушымта нигезендә.

- муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен база ставкасы (наемга алынган өчен база ставкасы), №2 кушымта нигезендә;

- торак биналарның милекчеләре өчен, капиталь ремонт өчен түләү күләме №3 кушымта нигезендә,

2. Әлеге карарны http://atnya.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм (http://pravo.tatarstan.ru) "хокукый мәгълүмат" порталында бастырырга;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

№ 1 Кушымта
Әтнә район башкарма комитеты
25.12.2019 №288 карарына

**Муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары яллаучыларга һәм торак урыннары милекчеләренә торак хезмәтләренә тарифлар**

| № . | Хезмәтләрнең исеме | **Ед. измерения руб/кв.м.** | **Тариф** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр. |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | сум/кв. м. (аена) | 0,75 | 0,78 |
| 2. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | сум/кв. м. (аена) | 4,12 | 4,20 |
| 3. | Электр белән тәэмин итү йорт эчендәге челтәрләргә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м. (аена) | 1,55 | 1,60 |
| 4. | Газ белән тәэмин итүнең гомумйорт инженерлык системасын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү | сум/кв. м. (аена) | 0,31 | 0,32 |
| 5. | Вентиляция каналларын һәм төтен юлларын техник хезмәт күрсәтү | сум/кв. м. торак бинаның гомуми мәйданы (аена) | 0,80 | 0,83 |

№ 2 Кушымта
Әтнә район башкарма комитеты
25.12.2019 №388 карарына

**Муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен**
**БАЗА СТАВКАСЫ**
**(наемга алынган өчен база ставкасы)**

| Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәт үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сума) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 ел. алып 30.06.2020ел. кадәр. | 01.07.2020ел. алып . 31.12.2020ел. кадәр. |
| База ставкасы яллау буенча | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 6,11 | 6,11 |

№ 3 Кушымта
Әтнә район башкарма комитеты
25.12.2019 №388 карарына

**Торак биналарның милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен**
**ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ**

| Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәт үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сума) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 ел. алып 30.06.2020ел. кадәр. | 01.07.2020ел. алып . 31.12.2020ел. кадәр. |
| Капиталь ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 6,11 | 6,11 |